# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге составына керүче Мельничная авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

2025 елнын 10 ноябере № 6

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35нче маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Мельничная авылы торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

1. Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегенең Мельничная авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлардан, тулы булмаган гаиләләрдән тыш, 2026 елда үзара салым акчаларын 1100 сум күләмендә кертергә.балигъ булмаган балаларны тәрбияләүче, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын, Россия Федерациясе Кораллы көчләрендәге контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне һәм аларның гаилә әгъзаларын үзара салым суммасының 50% күләмендә ташлама билгеләнгән.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.»

3. Җыенның нәтиҗәләрен кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Чепья авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Чепья авыл җирлеге башлыгы А. Г. Нотфуллин